# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлегенең Ленино авылында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2022 елның 21 октябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлегендә Ленино авылы халык җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл Ленино авыл җирлегендә Ленино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан,1 төркем инвалидлардан кала, 2023 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

-урамны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

-юлларны һәм тротуарларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

-кар чистарткыч җиһазлары сатып алу;

-җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

-су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, алгарышларны бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) Үзәк урамында».

3. Гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Ленино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/,» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ЛЕНИНСКОЕ
Р 06-585/14
СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ